ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21.06.2022 № 787

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга шәһәрендә Бөтенроссия Спас ярминкәсе Нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 17 июлендәге 969 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Халык сәнгать һөнәрләре турында» 1999 елның 6 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре турында» 2005 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга шәһәрендә Бөтенроссия Спас ярминкәсе Нигезләмәсен раслау турында» 2018 елның 17 июлендәге 969 номерлы карарына үзгәрешләр кертеп, Алабуга шәһәрендә Бөтенроссия Спас ярминкәсе турындагы Нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (1 нче кушымта).
2. «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга шәһәрендә Бөтенроссия Спас ярминкәсе Нигезләмәсен раслау турында» Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 17 июлендәге 969 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 17 июнендәге 751 номерлы карарын юкка чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 5DD9ADE894A62EB7F6C4DA0DBC7098E466BA
Владелец: Нургаянов Ленар Фаридович
Действителен с 03.12.2021 до 03.03.2023


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
21.06.2022 № 787

карарына 1 нче кушымта
.

## Алабуга шәһәрендә Бөтенроссия Спас ярминкәсе турында
## Н И Г Е З Л Ә М Ә

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәрендә ярминкә оештыру һәм уздыру тәртибен Алабуга шәһәрендә Бөтенроссия Спас ярминкәсе Нигезләмәсе билгели (алга таба - Ярминкәдә).

1.2. Әлеге Нигезләмә «Халык сәнгать һөнәрләре турында» 1999 елның 6 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, «Халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре турында» 2005 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Закон, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарының башка муниципаль норматив хокукый актлары нигезендә төзелде һәм гамәлгә ашырыла.

1.3. Ярминкәне гамәлгә куючылар булып түбәндәгеләр тора (алга таба – Гамәлгә куючылар):
- Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (килешү буенча);

-Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге.

1.4. Ярминкәнең оештыручылыры булып түбәндәгеләр тора (алга таба – Оештыручылар):
- Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты;

- «Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе (алга таба – Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы, килешү буенча);

- Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты (килешү буенча)

- Татарстан Республикасы  Сәүдә-сәнәгать палатасы (килешү буенча).

1.5. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан Ярминкәне уздыру вакыты билгеләнә. Ел саен август аеның беренче җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәрендә уздырыла.

1.6. Уздыру урыны (урыннары): Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Шишкин буалары территориясе, Ленин исемендәге мәйдан, «Мәйдан» шәһәр тамаша үзәге («Яшьләр» стадионы), Казан, Гассар, Яр Буе, Говоров, Олы Покров, Спас урамнары..

## 2. Ярминкәнең максаты һәм бурычлары

2.1. Ярминкә бердәм мәдәни киңлекне формалаштыру, гражданнарның төрле төркемнәренең мәдәни кыйммәтләреннән һәм мәгълүмати ресурсларыннан файдалану мөмкинлеген булдыру, тарихи-мәдәни традицияләргә тирән хөрмәт хисе тәрбияләү, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни потенциалын, мирасын саклау, файдалану, тәҗрибә уртаклашу һәм үстерү өчен шартлар тудыру, мәдәният өлкәсенең базар шартларына җайлашуын тәэмин итү, еллар дәвамында халык һөнәрчелеген саклап калу максатларында үткәрелә.

2.2. Ярминкәнең бурычлары:

- Алабуга шәһәрендә ел саен үткәрелә торган Ярминкәне уздыру гореф-гадәтләрен (традициясен) дәвам итү;
- ярминкә сәүдәсенең иң яхшы традицияләрен торгызу;
- Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасында традицион һөнәрчелек культурасын һәм халык сәнгать һөнәрләрен торгызу, саклап калу һәм аны үстерү;
- милли халык сәнгать кәсепләренең күптөрлелеген саклап калу;
- декоратив-гамәли сәнгатьне үстерү;
- халык сәнгатен һәм фольклорын төрле күренешләрендә популярлаштыру;
- халык сәнгате, декоратив-гамәли сәнгать һөнәрләрен. халык осталарын үстерүдә ярдәм итү;
- Россия Федерациясе төбәкләре һәм Татарстан Республикасы районнары арасындагы икътисадый һәм мәдәни хезмәттәшлекне ныгыту;
- вакыйгалар һәм мәдәни-танып-белү туризмын үстерү;
- талантлы халык сәнгать һөнәрләрен, декоратив-гамәли сәнгать осталарын, һөнәрчелек традицияләрен саклап калган һәм алга таба иҗат эшчәнлеген стимуллаштыручы халык осталарын җәлеп итү һәм аларны ачыклау, барлау;
- Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы халык һөнәрчелеге, декоратив-гамәли сәнгать осталарының мәгълүматлар банкын формалаштыру;
- халык һөнәрчелеге эшләнмәләрен, декоратив-гамәли сәнгать осталары, халык һөнәрчелеге эшләрен күрсәтү һәм сату;

- халык сәнгать һөнәрләре, декоратив-гамәли сәнгать осталары, халык һөнәрчелеге өлкәсендә эшләүче урта һәм кече кәсәбә (бизнес) вәкилләре арасында эшлекле аралашу өчен уңай шартлар тудыру;

- ярминкә сәүдәсенең традицион үзәге буларак, Алабуга шәһәре образын формалаштыру;

- Алабуга дәүләт музее фондын - тулыландыру максатларында, аны халык сәнгать һөнәрләре, декоратив-гамәли сәнгать осталары, халык осталары эшләнмәләренең традицион кәсепләрнең бай коллекциясенә ия булу;

- Алабуга шәһәрендә уздырылган Спас ярминкәсенә туристларны күпләп җәлеп итүне тәэмин итү;

- җыр һәм музыка иҗатында фольклор традицияләрен (йолалаларын) саклап калу һәм аны популярлаштыру.

## 3. Ярминне оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү

3.1. Ярминкәне оештыру һәм уздыру түбәндәге финанс чаралары хисабыннан формалаша:

- Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы чаралары;

-Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы счетына дәүләт йөкләмәсен үтәүгә субсидияләр рәвешендә кергән Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы чаралары;

- Ярминкәдә катнашучыларның теркәлү түләүләре (взнослары);

- физик, юридик затларның, индивидуаль (шәхси) эшкуарларның ирекле иганәләре;

- Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган башка чыганаклар.

## 4. Катнашу өчен сайлап алу критерийлары

4.1. Ярминкәдә теләсә нинди юридик яки физик зат, шәхси эшкуарлар, «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар (үзмәшгуль булып теркәлгәннәр), шулай ук эшчәнлекләре Ярминкәдә катнашу максатларына һәм бурычларына туры килә торган һәм рәсем, декоратив - гамәли сәнгать осталарының, рәссамнарының иҗади коллективлары  һәм әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә Ярминкәдә катнашучылар категориясенә туры килгүчеләр катнаша ала.

4.2. Ярминкәдә катнашучылар түбәндәге 7 төр категориягә бүленә:

**1 нче төр категориягә -** халык сәнгать һөнәрләре осталары, декоратив-гамәли сәнгать осталары, халык осталары, һөнәрчеләр, халык сәнгать һөнәрләре эшләнмәләре ясау белән шөгыльләнүче үзенчәлекле һәм профессиональ рәссамнар, юридик затлар, декоратив-гамәли сәнгать эшләнмәләре ясау белән шөгыльләнүче шәхси эшкуарлар, һөнәрче артельләр, берләшмәләр, предприятиеләр һәм фирмалар, тарихи-мәдәни һәм музей кыйммәте булган антиквар эшләнмәләр, эшләнмәләр белән катнашучылар, халык сәнгать һөнәрләрен һәм кәсепләрен үстерү үзәкләре

әгъзалары, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының һөнәрчелек һәм декоратив-гамәли сәнгать палатасы әгъзалары.

Заявкалар (гаризалар) катнашучылар тарафыннан, Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы, Идарәче компания белән килешү буенча, түбәндәге рәсми сайт аша юлланыла: **спасскаяярмарка.рф.**

Ярминкәдә катнашучыларның әлеге категориясендә катнашуга гаризалар каралганда түбәндәгеләр исәпкә алына:

- кул эше;
- үз җитештерүе;
- традицион һөнәрчелек технологияләрен куллану;
- табигый материалларны куллану;
- эксклюзивлык, үзенчәлекле дизайн;
- эшләнмәләрнең төрлелеге, яңалыгы һәм югары сыйфаты.

Ярминкә барышы чорында өч көн дәвамында мастер - класслар уздыру әлеге категория өчен мәҗбүри шарт булып тора. Әлеге категориядә катнашучыларны урнаштыру урыны «Яшьләр» стадионында каралган.

**2 нче төр категориягә** – юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар, үзләре эшли торган, ваклап сату һәм бал һәм умартачылык продуктлары белән ваклап сату белән шөгыльләнүче үзмәшгульләр.

**3 нче төр категориягә** - үсемлекләрне (үсентеләр, утырту материаллары, куаклар, чәчәкләр, орлыклар, бакча инструментлары һ.б.) ваклап сату белән шөгыльләнүче юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар, үзмәшгульләр.

**4 нче төр категориягә** - юридик затлар, үз-үзләрен эш белән тәэмин итүче, индивидуаль эшкуарлар - ял һәм ял итү өлкәсе вәкилләре (батутлар, карусель, тир, бассейн, веломобил, дартс, аттракционнар һ.б.лар).

**5 нче төр категориягә** - азык-төлек товарлары (кулинария азыклары, пешерелгән камыр ашлары, казылык, тутырма кебек ит әйберләре, сөт ризыклары, балык, яшелчә, җиләк-җимеш, бадлар, алкогольсез эчемлекләр, хәлва, прәннек, конфет, как, ширбәт, рәхәт-лукум, мармелад, чәй, чикләвек, кипкән җиләк-җимешләр, аштәмләткечләре, татлы мамык, попкорн, карамельле алма, кукуруз, коктейль, сок, су һ.б.) белән ваклап һәм вак-төяк сату белән шөгыльләнүче юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар, үзмәшгульләр.

**6 нчы төр категориягә** - азык-төлек булмаган товарлар (әйберләр) (баш киемнәре, текстиль, трикотаж, йон, күн эшләнмәләр, өске кием, аяк киеме, чатырма, сумка, акча янчыгы, кухня өчен кирәк-яраклар, көнкүреш химиясе, бизәнү әйберләре, бижутерия, күзлек, ювелир эшләнмәләр, таштан ясалган әйберләр, шәмнәр, китаплар, сәгатьләр, сувенирлар, уенчыклар, кул эшләре, зоотоварлар, йорт хайваннары, балыклар, ташбакалар һ.б.) ваклап һәм вак-төяк сату итүче юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар, үзмәшгульләр.

**7 нче төр категориягә** - җәмәгать туклануы өлкәсе вәкилләре (кафе, рестораннар) - юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар, үзмәшгульләр.

Заявкалар (гаризалар) катнашучылар тарафыннан түбәндәге рәсми сайтта: **спасская-ярмарка.рф,** яки турыдан-туры идарәче компаниясендә рәсмиләштерелә.

## 5. Ярминкәгә әзерлек һәм үткәрү тәртибе

5.1. Ярминкәгә әзерлек һәм аны уздыру өчен оештыру комитеты төзелә, аның составы Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана (алга таба – Оештыру комитеты).

5.2. **Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты:**

- Оештыру комитеты составын төзү турындагы карар нигезендә, әлеге Нигезләмә нигезендә Ярминкәне уздыруга карата оештыру-техник чараларын башкаручы - идарәче компания билгеләнә.

- Ярминкәнең программасын, Ярминкә узачак территориядә катнашучыларны урнаштыру схемасын раслый;

- кешеләр күпләп җыела торган урыннардан,объектлардан гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычын, сакланышын тәэмин итә;

- чараны уздырганда объектның (территориянең) һәм җәмәгать тәртибен саклау максатыннан нженер-техник чаралар белән тәэмин итә;

- «Мәйдан» ШТҮ («Яшьләр» стадионында) душ, бәдрәфләрнең тәүлек буе эшләвен тәэмин итә, телефоннар өчен зарядка алу урыннары булу-булмавын ачыклый һәм аның бәясен билгели, объектның (территориянең) чараны уздыруга әзерлеген тикшерә.

- тавыш көчәйтүче һәм яктылык аппаратурасы булачак төп сәхнәнең урынын билгели;

- Ярминкә чараларын үткәрү өчен җир кишәрлекләрен кабул итү-тапшыру актларын идарәче компаниягә тапшыра;

- Спас ярминкәсенең төп сәхнәсендә җәлеп ителгән шәһәр иҗат коллективларының көн саен 9.00 сәгатьтән 22.00 сәгатькә кадәр чыгыш ясауларын оештыра;

- «Вдохновение» («Илһам») дигән авторлык җырлары фестивален уздыра.

5.3. «**Идарәче компания»:**

- «спасскаяярмарка.рф» сайтының корректлы эшен оештыра;

- «спасскаяярмарка.рф» сайтында заявкалар (гаризалар) кабул итүне һәм катнашу өчен түләү эшен оештыра;

- Ярминкәдә катнашучыларның заявкаларын тикшерә һәм катнашучыларның 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7 нче төр категорияләрен билгели**;**

- Ярминкәдә катнашу өчен бирелгән барлык заявкаларның (гаризаларның) дөрес, төгәл тутырылышын тикшерә;

- Ярминкәдә катнашучылардан кергән барлык категория гаризаларын эшкәртү юлы белән Ярминкәдә катнашучылар формалашуның автоматлаштырылган системасын оештыра һәм барлый;

- Ярминкәдә катнашуга кергән заявка (гариза) Идарәче компания операторы тарафыннан кандидатның таләпләргә, критерийларга һәм Ярминкәдә катнашу шартларына туры килү-килмәвен тикшерә, әлеге Нигезләмә тәлапләреннән чыгып, 5 эш көне дәвамында Ярминкәдә катнашучы билгеләнә;

- Ярминкәне уздыру барышында катнашу шартлары бозылу ачыкланган очракта, әлеге хокук бозуларны бетерү турында телдән кисәтү ясый һәм аның кичекмәстән үтәлүе зарури;

- катнашучы яки аның хезмәткәрләре (вәкилләре) Ярминкәне уздыру барышында ачыкланган катнашу шартлары бозылудан баш тарткан очракта, алга таба катнашудан читләштерелә торган тиешле акт төзелә, теркәлү взносы кире кайтарылмый;

- Ярминкәдә катнашучылардан теркәү взносларын, ирекле иганәләрне һәм закон белән тыелмаган башка предприятиеләрдән һәм оешмалардан кертемнәрне кабул итә, алга таба аларны бары тик Ярминкәне оештыруга һәм уздыруга гына юнәлтә;

- Бөтенроссия Спас ярминкәсе сайтында теркәлү схемасы нигезендә «Мәйдан» ШТҮ («Яшьләр» стадионы), Шишкин буалары, Яр буе урамы, Гассар урамы, Казан урамы, Спас урамы, Олы Покров урамы, Говоров урамы Бөтенроссия Спас ярминкәсе билгеләү гамәлгә ашыра;

- Спас ярминкәсендә катнашучыларны, аларның категориясен исәпкә алып, түләүле урыннар буенча урнаштыра;

- килешү төзи яки мөстәкыйль рәвештә түбәндәге хезмәтләр күрсәтә:

- - ярминкә киңлеген һәм шул исәптән Ленин мәйданындагы «Осталар ишегалды» 5 көн дәвамында саклау;

- ярминкә дәвамында биотуалет урнаштыру һәм аларга хезмәт күрсәтү;

- сәхнәләрне һәм тавыш көчәйтү һәм яктылык аппаратурасын урнаштыру һәм демонтажлау;

- VIP трибунасындагы кунакларны тукландыру;

- Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы белән килештерелгән күләмдә Чаң чыңы фестиваленендә катнашучыларга: бейджлар, истәлекле бүләкләү өчен конвертлар, катнашучылар өчен дипломнар, афишалар кертелгән мәгълүмат тарату материалларын әзерли;

- Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы белән килештерелгән күләмдә реклама-мәгълүмат эшен оештыра (панельләрнең цифрлы видеоларында реклама, баннер ясау, радиода реклама, Спас ярминкәсе турында фото-видеоролик әзерли);

- Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы балансында урнашкан «Мәйдан» шәһәр тамаша үзәге территориясендә («Яшьләр» стадионы) ярминкә киңлеген тәэмин итә. Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы белән килештереп, әлеге мөлкәтне транспортировкалауны, монтажлауны һәм демонтажлауны һәм сүтү кебек эшләр башкара.

- Спас ярминкәсе һәм Чаң чыңы фестивале концерт программасында катнашучыларның музыка уен коралларын һәм җиһазларын ярминкә киңлеге территориясенә ташуны гамәлгә ашыра;

- Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы белән килешү нигезендә, ярминкә киңлеген сәнгатьчә бизәүне тәэмин итә.

5.4. **Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы:**

- декоратив-гамәли сәнгать осталарын, халык осталарын ярминкәгә чакыра элемтәләр урнаштыра;

- Бөтенроссия Чың чыңы фестивале кысаларында, концертка 2 – Чың чаңы оештыра һәм үткәрә;

- Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы балансында булган ярминкә киңлеген чатырлар белән тәэмин итә, аларны монтажлау, демонтажлау өчен идарәче компаниягә ярминкәдә урнаштыру өчен  тапшыра;

- 1 нче төр категорияле Спас ярминкәсендә катнашучыларына каталоглар, бейджлар, бүләкләү өчен дипломнар, конвертлар, истәлекле бүләкләр, афишалар кергән тарату материаллары әзерли;

- идарәче компания белән берлектә килештерелгән күләмдә Бөтенроссия Чаң чыңы фестивалендә катнашучылар өчен: бейджлар, истәлекле каталоглар, бүләкләү өчен конвертлар, дипломнар, афишаларны үз эченә алган мәгълүмати тарату материаллары әзерли;

- Ярминкәгә килгән 1  нче төр категорияле катнашучыларна Алабуга шәһәренең тулай торакларына (катнашучыларның үзләре хисабына) урнаштыруны оештыра;

-Яярминкә кысаларында күләмдә Бөтенроссия Чаң чыңы фестивален оештыра һәм уздыра;

-фольклор коллективларны, чаң сугучыларны, музыкант-мультиинструменталистларны чакыруны һәм Ярминкәнең төп сәхнәсендә Чаң чыңы фестивалендә чыгыш ясаулырын оештыра;

- Бөтенроссия Чаң чыңы фестиваленә чакырылган катнашучылар өчен Алабуга шәһәрендә яшәү, туклану һәм аларның килеп-китеп йөрүләрен тәэмин итә;

- Ярминкәне һәм Бөтенроссия Чаң чыңы фестивале фотоларын теркәүне (фотога төшерүләрне)  (фотофиксация) оештыра;

- идарәче компания белән берлектә килештерелгән күләмдә реклама-мәгълүмат эшен оештыра (панельләрнең цифрлы видеоларында реклама, баннер ясау, радиода реклама, Спас ярминкәсе турында фото-видеоролик ясау);

- «Иң яхшы мастер» (20 кеше) номинацияләрендә осталар (1 нче төр категориядә катнашучылар) арасында җиңүчеләрне билгеләү буенча жюри эшен оештыра һәм бүләкләү уздыра;

- халык сәнгате өлкәсендә иң яхшы 5 фольклор иҗат коллективын «Халык традицияләрен саклап калу өчен» бүләкләүне оештыра;

-мультиинструменталистлар музыкантлары, фольклор коллективларының, чаң кагучыларның, борынгы музыка уен коралларында башкаручыларның һәм Бөтенроссия чаң тавышы фестивалендә катнашучыларның башка категорияләренең 7 номинациясе буенча

бүләкләүне һәм Ярминкә көннәрендә уздырыла торган 2 нче Чаң чыңы - концерт һәм Бөтенроссия Чаң чыңы фестивале буенча бүләкләүне оештыра;

- Спас ярминкәсе көннәрендә фольклор коллективлары һәм чаң кагучылар катнашында концерт программасын оештыра.

- Ленин мәйданында «Осталар ишегалды» эшен оештыра (30 катнашучы);

-идарәче компания Спас ярминкәсе көннәрендә уздырган концерт программасы репертуарын формалаштыруда катнаша;

-музейлар эшен 21:00 сәгатькә кадәр оештыра, туристик һәм теплоход төркемнәре, шәһәр кунакларын кабул итә.

5.5. **<u>Ярминкә программасына түбәндәгеләр керә</u>**:

- халык сәнгате һәм декоратив-гамәли сәнгать эшләнмәләрен сату-күргәзмәсе;
- Бөтенроссия Чаң чыңы фестивале;
- 1 нче төр категорияле катнашучыларның мастер-класслары;
- фольклор, цирк һәм башка иҗат коллективлары чыгышлары;
- ярминкәгә килүчеләр өчен халык уеннары һәм турнирлар;
- күргәзмә-сату: азык-төлек, авыл хуҗалыгы предприятиеләре һәм эшкәртүче сәнәгать продукциясе товарлары;
- авыл хуҗалыгы продукциясен сату;
- халык куллану товарларын сату;
- җәмәгать туклануы урыннарын оештыру;
- аттракционнар һәм прокат пунктлары белән уен мәйданчыклары оештыру;
-һәм башка чаралар.

5.6. Ярминкәдә катнашучылар үз әйберләрен (мөлкәтен) югалткан очракта оештыручылар, гамәлгә куючылар, идарәче компания җаваплылык тотмый.

5.7. Ярминкәне оештыруны, уздыруны контрольдә тоту аның оештыручылары - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты, Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы һәм идарәче компания тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5.8. Ярминкәдә катнашучылар түбәндәгеләргә бурычлы:

- «Спас ярминкәсе» массакүләм чараларында катнашучыларга, тамашачыларга һәм башка катнашучыларга карата ихтирамлы мөнәсәбәт күрсәтергә, үз гамәлләре белән алар тарафыннан хокук бозуларны булдырмаска һәм аларның кагыйдәләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга юл куймаска;
- ниндидер йомыш белән килүчеләргә, сатып алучыларга, тамашачыларга һәм башкаларга карата ихтирамлы мөнәсәбәт күрсәтергә, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләрне үтәргә, халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итәргә, әйләнә-тирә мохитне сакларга һәм Алабуга шәһәрендә Бөтенроссия Спас ярминкәсе Нигезләмәсенең таләпләрен үтәргә;

- оператив эш өчен уңайлы формула (шартнамә) таләпләрен үтәргә;

- Ярминкә Оештыручылары һәм идарәче компания хезмәткәрләре тарафыннан законга һәм әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләрне үтәргә.

5.9. Ярминкәдә катнашучылар җәмгыятьтә экстремистик идеяләрнең таралуы, раса, милли яки дини ызгыш кузгатуы, шулай ук көч куллануны, порнография, наркомания, токсикомания, эчкечелек һәм башка зарарлы гадәтләрне пропагандалау өчен җаваплы.

Ярминкә тәмамланганнан соң халык сәнгать һөнәрләре осталары продукциясе килешү һәм исәптә кулланыла торган товар документы (накладная) белән, ике яклы шартнамә буенча һәм законда билгеләнгән тәртиптә Алабуга дәүләт музей-тыюлыгына гамәлгә ашыруга тапшырылырга мөмкин.

## 6. Ярминкәдә катнашу шартлары

6.1. Ярминкәдә катнашырга теләк белдергән барлык затлар (1 нче категорияле катнашучылар өчен) 1 нче кушымтада һәм (2, 3, 4, 5, 6, 7 нче төр категорияләрдәге катнашучылар өчен) 2 нче кушымтада бирелгән үрнәктәге гаризаларны рәсмиләштерәләр.

6.2. Заявка (гариза) рәсми сайтта катнашучы категориясенә карап, ярминкәдә катнашырга теләүче затлар тарафыннан биреләгән рәсми сайтында күрсәтелә: **спасскаяярмарка.рф)**. заявкалар (гаризалар) бирү вакыты Спас ярминкә рәсми сайтында күрсәтелә: **спасскаяярмарка.рф)**.

6.2.1. 1 нче төр категориядәге катнашучылар түбәндәге юнәлешләр буенча рәсми сайтта заявка (гариза) тутыралар **спасскаяярмарка.рф:**

- бизәкле хәтфә келәм сугу;
- сәйлән белән алтын җепләр катнаштырып, төрле ысуллар белән чигү;
- сәйлән, макрама, челтәрләр үрү;
- бизәкле үрем, югары сәнгать трикотажы;
- тиредән нәфис эшләнмәләр;
- корама (мозаика, аппликация;
- халык костюмы һәм аның элементлары;
- зәркән эшләнмәләре һәм бизәнү әйберләре;
- нәфис керамика, фарфор, фаянс;
- чүлмәк ясау әйберләре;
- агач һәм ташка кисеп бизәк төшерү (резьба);
- каен агачы тузыннан үрү һәм кисү;
- ботаклардан үрү;
- урман скульптурасы, салам, кап, чага, фитокомпанияләр эшләнмәләре;
- эретеп ясау, чүкеп ясау, формаларга кою, филигрань;
- агач, ефәк, метал белән бизәү;
- рәсем, лак миниатюрасы, иконода язу сәнгате;
- уенчыклар, сувенирлар;

- башка халык һөнәрчелеге эшләнмәләре, декоратив-гамәли сәнгать осталары, халык һөнәрчелеге эшләнмәләре, шул исәптән авторлык техникаларында эшләнгән;
-тарихи-мәдәни һәм музей кыйммәте булган антиквар эшләнмәләр һәм эшләнмәләр.

Ярминкәдә катнашучылар үз эшләнмәләрен һәм төбәкләрен матур итеп бизәлгән баннер, планшет яки тасмалар белән тәкъдим итәләр, анда торак пункт исеме дә күрсәтелгән булырга тиеш.

Оештыручылар 1 нче төр категориядә катнашучыларның авторлык эшләнмәләрен фотога һәм видеога төшерү хокукына ия. Барлык эшләр дә автомобильләр турында мәгълүмат кушып имзаланган яки беркетелгән этикетка ия булырга тиеш.

1 нче төр категориядә катнашучы түләүсез рәвештә, Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы фондына халык сәнгать һөнәрләре эшләнмәләре коллекциясен комплектлау максатыннан чыгып бер югары сыйфатлы иҗади эшен (әйберен) Россия Федерациясе музей фондына тапшыра.

6.2.2. Ярминкәдә барлык төр катнашучылар өчен түбәндәге юнәлешләр буенча рәсми сайтта, **спасскаяярмарка.рф** заявка (гариза) тутыра алалар.

Барлык төр катнашучыларны урнаштыру расланган схема нигезендә гамәлгә ашырыла.

6.3. Ярминкәдә барлык төр катнашучылар өчен 3 нче кушымтада бирелгән реквизитлар буенча теркәү взносын кертергә кирәк.

Түләү әлеге Нигезләмәнең шартлары нигезендә «спасскаяярмарка.рф» сайтында гамәлгә ашырыла. Түләү килмәгән очракта, бронь билгеләнми. Схемада урынны броньлау «спасскаярмарка.рф» сайтында гамәлгә ашырыла.

6.3.1. Оештыручылар чатырларында бирелә торган 1 категориядәге катнашучылар өчен теркәлү взносы 1200 (бер мең ике йөз) сум тәшкил итә, расланган схема буенча: 1 эш урыны (киңлеге 1 м, тирәнлеге 2 м һәм биеклеге 3 м дан артмаган), калган урыннар өчен-бер эш урыны өчен 1000 (бер мең) сум (киңлеге 1 м, тирәнлеге 2 м һәм биеклеге 3 м дан артмаган. Бер катнашучы 5 тән дә артык урын алмаска тиеш.

6.3.2. 2 категорияле катнашучылар өчен теркәлү взносы 1 урын өчен 2500 (ике мең биш йөз) сум тәшкил итә (киңлеге 1 м, киңлеге 2 м һәм биеклеге 3 м дан артмаган). Бер катнашучы 12 дән дә артык урын алмаска тиеш.

6.3.3. 3 категориядә катнашучылар өчен теркәү взносы 1 урын өчен 2500 (ике мең биш йөз) сум (1 м киңлек, 2 м тирәнлек һәм 3 м дан артык булмаган биеклек) тәшкил итә. Бер катнашучы 12 дән дә артык урын алмаска тиеш.

6.3.4. 4 нче төр категориядәге катнашучылар өчен: 4 категориядә катнашучылар өчен теркәү взносы 15 000 (унбиш мең) сум тәшкил итә - 50

квадрат метрга кадәр, беркетүне, коймаларны да кертеп, расланган схема нигезендә нигезләнгән. Бер катнашучы 3 сәүдә урыны алырга мөмкин.

6.3.5. 5 нче төр категориядә катнашучылар өчен: 1 метр өчен 2500 (ике мең биш йөз), 3500 (өч мең биш йөз), 6000 (алты мең) сум (сәүдә урыны) 1 урынга (1 м - киңлектәге, 2 м - тирәнлектәге һәм 3 м дан артык булмаган - биеклеге) бәйле рәвештә. Бер катнашучы расланган схема буенча артмаган ун ике сәүдә урыны (чатыр) алырга мөмкин. Бер катнашучы 12 дән дә артык урын алмаска тиеш.

6.3.6. 6 нчы төр категориядә катнашучылар өчен: 2500 (ике мең биш йөз) сум, 3500 (өч мең биш йөз) сум, 6000 (алты мең) сум тәшкил итә, урнашу урынына карап (1 м киңлектәге, 2 м тирәнлектәге һәм 3 м дан артык булмаган биеклектә). . Бер катнашучы 12 дән дә артык урын алмаска тиеш.

6.3.7. Урын өчен расланган схема нигезендә, 7 нче төр категориядә катнашучылар өчен теркәү взносы 50 000 (илле мең) сум тәшкил итә (8 м киңлектә һәм 3 м тирәнлектә). Бер катнашучыга бары тик 1 сәүдә урыны гына бирелә.

6.4. 1 нче төр категориядә катнашучылар арасындагы 1, 2, 3 төр төркем инвалид статусы һәм аны раслаучы документы, ягъни белешмәсе, таныклыклыгы күрсәтелгәндә, 350 сум күләмендә теркәү взносының ташламалы бәясе бирелә.

Ташлама алу хокукын гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә рәсми сайтта инвалид статусын раслаучы - белешмәсе, таныклыгы үрнәктә китерелгән тәртиптә ягъни документның электрон рәвештә күчермәсен теркәү кирәк.

6.5. Юл сәфәре (командировка) чыгымнары, әйберләрне оештыру кертеме һәм китерү өчен Ярминкәдә катнашучы яки җибәрүче оешма түли.

6.6. Теркәлү өчен түләү рәсми сайтта теркәлгәндә башкарыла: **спасскаяярмарка.рф** исәп-хисапслау юлы белән, яисә яисә акчалата идарәче компания кассасына түләнә.

6.7. Теркәлгәннән һәм теркәлү кертеме түләгәннән соң катнашучының рәсми сайтында Ярминкә уздыру урынында "катнашучы паспорты" бирелә. Катнашучының паспорты хокук саклау органнары хезмәткәрләре, Ярминкәне оештыручылар һәм идарәче компания таләбе буенча, Ярминкәне уздыру урынында урнаштырганда һәм Ярминкәдә күрсәтелгән категория буенча катнашу хокукын раслый.

6.8. Заявка (гариза) расланганнан соң яки ярминкәдә катнашу туктатылганнан соң, ярминкәдә катнашудан үз иреге белән баш тарту очрагы булганда, теркәлү взнослары кире кайтарылмый.

6.9. Ярминкәдә катнашучыларга консультация бирү Алабуга шәһәре, Казан урамы, 15а йорты адресы буенча билгеләнгән эш режимы нигезендә гамәлгә ашырыла:

8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр Ярминкә башланырга ике көн кала;

6.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр Ярминкәнең беренче көнендә.

6.10. Ярминкәдә катнашучыларның шәхси транспортлары товарлар һәм җиһазлар кертү-чыгару өчен рөхсәт ителә:

Ярминкәнең беренче көненә кадәр булган көн – чикләүләрсез;

Ярминкәнең беренче көне-8.00 сәгатькә кадәр;

Ярминкәнең икенче көне-тыелган;

Ярминкәнең өченче көне-18.00 сәгатьтән.

Идарәче компания, Оештыручылар, һәм / яки хокук саклау органнары хезмәткәре, әгәр мондый юл юл гражданнарның тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч тудырса һәм / яки гадәттән тыш хәл барлыкка килүгә ярдәм итсә, Ярминкә территориясенә узудан баш тартырга хокуклы.

6.11. Автомобильләрне урнаштыру өчен түбәндәге адрес буенча тукталыш каралган: Алабуга шәһәренең Яр буе урамыннан түбәнрәк (кадастр номеры: 16:47:000000:1197) расланган схема нигезендә.

## 7. Нәтиҗәләр ясау һәм бүләкләү

7.1. Ярминкә кысаларында Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы тарафыннан оештырылган «Иң яхшы халык сәнгать һөнәрләре остасы» бәйгесе үткәрелә. Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы каршында махсус оештырылган Сәнгать советы ярминкәдә тәкъдим ителгән халык сәнгать һөнәрләре эшләгән әйберләрне түбәндәге критерийлардан чыгып бәяли:

- үзенчәлекле йола, гореф-гадәтләрне һәм милли колоритны саклап калу һәм гамәлгә ашыру;
- югары сәнгать дәрәҗәсе;
- эшләү сыйфаты, оригинальлеге.

7.2. Иң яхшы декоратив-гамәли сәнгать осталарын бүләкләү өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан «Халык традицияләрен саклап калган өчен» декоратив-гамәли сәнгать өлкәсенә 5748 (биш мең җиде йөз кырык сигез) сум күләмендә акчалата премияләр 1әм 20 диплом каралган, алар Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы генераль директоры боерыгы белән расланган сәнгать Советы турындагы Нигезләмә нигезендә билгеләнә һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы, Алабуга муниципаль районы вәкилләре тарафыннан тапшырыла.

7.3. Ярминкә көннәрендә чыгыш ясаучы иң яхшы фольклор иҗат коллективларын бүләкләү өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан «Халык традицияләрен саклап калган өчен»


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

халык сәнгате өлкәсенә 5748 (биш мең җиде йөз кырык сигез) сум күләмендә акчалата премияләр һәм 5 диплом каралган, алар Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы генераль директоры боерыгы белән расланган сәнгать Советы турындагы Нигезләмә нигезендә билгеләнә һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы, Алабуга муниципаль районы вәкилләре тарафыннан тапшырыла.

7.4. Ярминкә көннәрендә үткәрелә торган Бөтенроссия Чаң чыңы фестивалендә һәм 2-чаң кагу концертларында катнашкан мультиинструмент музыка осталарына, фольклор коллективларга, чаң кагучыларга, борынгы музыка коралларында башкаручыларга һәм катнашучыларның башка төр категорияләренә 23000 (егерме өч мең) сум күләмендә - 7 төр номинациягә премияләр каралган, алар Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы генераль директоры боерыгы белән расланган сәнгать Советы турындагы Нигезләмә нигезендә билгеләнә.

7.5 Бөтенроссия Спас ярминкәсенең һәм Чаң чыңы фестиваленең ябылу тантанасында гамәлгә куючылар һәм оештыручылар катнашында бүләкләү уздырыла.

**Спас ярминкәсе Нигезләмәсенә**
**1 нче кушымта**

## 1 нче төр категория катнашучылары өчен заявка (гариза) формасы

1. Катнашучының тулы фамилиясе, исеме, атасының исеме *:

________________________________________________________________
_

2. Катнашучының  почта адресы индексы белән *:

________________________________________________________________
_

3. Шәһәр коды белән элемтә өчен телефоннар (факс), һичшиксез, кәрәзле телефоннар *:

________________________________________________________________
_

4. E-mail* һәм социаль челтәрләре битләреннән сылтама * :

________________________________________________________________
_

5. Эшчәнлек төре, экспонатлар турында мәгълүматлар (кыскача)*:

________________________________________________________________
_

6. Спас ярминкәсендә узачак мастер - класс тасвирламасы *:

________________________________________________________________
_

7. Озата баручының (фамилиясе, исеме, атасының исеме, яше)*:

________________________________________________________________

8. Үз җиһазлары булу (өстәл, урындык, стенд, чатыр, челтәр-япма һәм башкалар, күләме, үлчәме,  саны (әгәр булса) *:

_________________________________________

9. Ярминкәләрдә, халыкара күргәзмәләрдә катнашу (кайларда):

________________________________________________________________
_

10. Күз алдында тотылган килү көне* ___________________________

**БАРЛЫК КАТНАШУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА!!!**

(*) белән билгеләнгән кырларны тутыру мәҗбүри.!
- Тиешенчә ахырына кадәр тутырылмаган заявкалар (гаризалар)  кабул ителми!
- Зинһар өчен, Спас ярминкәсе турындагы Нигезләмәне игътибар белән укыгыз!
- Телефон номерларын тулысынча күрсәтергә кирәк (шәһәр коды белән бергә), телефоннар гамәлдә булырга тиеш.  Телефон номерын алыштырган очракта, бу турыда оештыручыларга тиз арада хәбәр итәргә кирәк.
- Катнашучылар составында үзгәрешләр булган очракта да оештыручыларга тиз арада хәбәр итегез.
- Катнашу өчен заявкалар (гаризалар) Спас ярминкәсенең рәсми сайтында тутырыла: спасскаяярмарка.рф.

**Спас ярминкәсе Нигезләмәсенә**
**2 нче кушымта**

**2, 3, 4, 5, 6, 7 нче төр категорияле катнашучылар өчен заявка (гариза) формасы**

Катнашучының категориясе________________________
Ил _____________________________________________
Төбәк___________________________________________
Теркәлү адресы__________________________________
Шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (предприятиенең исеме)____________________
Салым түләүченең шәхси тәңгәлләштерү саны (ИНН)_____
Төп дәүләт теркәве номеры (ОГРН) ______________________
Элемтә өчен телефон__________________________________
E-mail ______________________________________________
Ассортимент исемлеге ________________________________

Катгашучының имзасы:______________

**БАРЛЫК КАТНАШУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА!!!**

(*) белән билгеләнгән кырларны тутыру мәҗбүри.!
- Тиешенчә ахырына кадәр тутырылмаган заявкалар (гаризалар) кабул ителми!
- Зинһар өчен, Спас ярминкәсе турындагы Нигезләмәне игътибар белән укыгыз!
- Телефон номерларын тулысынча күрсәтергә кирәк (шәһәр коды белән бергә), телефоннар гамәлдә булырга тиеш. Телефон номерын алыштырган очракта, бу турыда оештыручыларга тиз арада хәбәр итәргә кирәк.
- Катнашучылар составында үзгәрешләр булган очракта да оештыручыларга тиз арада хәбәр итегез.
- Катнашу өчен заявкалар (гаризалар) Спас ярминкәсенең рәсми сайтында тутырыла: спасскаяярмарка.рф.

**Спас ярминкәсе Нигезләмәсенә**
**3 нче кушымта**

**Оештыру взносларын күчерү өчен**
**банк реквизитлары**

| | |
|---|---|
| Исәп-хисап счеты | |
| Алучы | |
| Банкның тулы исеме | |
| БИК | |
| Салым түләүченең шәхси тәңгәлләштерү саны (ИНН | |
| Исәпкә куелу сәбәбе коды (КПП) | |
| Бюджет классификациясе коды (КБК) | |
| ОКТМО (муниципаль берәмлекләр территорияләренең гомумроссия классификаторы) | |

Түләүне билгеләү күләме: Спас ярминкәсенә теркәү взносы